МИНИСТЕРСТВО КУЛЬТУРЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

28.08.2015 г. Казань № 941 од

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең иң яхшы хезмәткәрләренә ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» 22.12.2008 ел, № 1015 боерыгына үзгәрешләр кертү турында

**БОЕРЫК БИРӘМ:**

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең иң яхшы хезмәткәрләренә ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» 22.12.2008 ел, № 1015 боерыгы белән (Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 11.11.2013 ел, № 934 о/д боерыгы белән кертелгән үзгәрешләр белән) расланган мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең иң яхшы хезмәткәрләренә ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибе турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.5. пунктта «сентябрь» сүзен «август» сүзенә алмаштырырга;

2 нче бүлекне түбәндәге эчтәлекле 2.7. пункты белән тулыландырырга:

«2.7. Бу Нигезләмәнең 2.6. пунктында күрсәтелгән документлар һәм материаллар гариза бирүчегә кире кайтарылмый»;

4.1. пунктта «авторитетлы һәм компетентлы» сүзләрен төшереп калдырырга;

5.1. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Грант алу өчен номинация таләпләренә туры китереп язылган гаризалар һәм алар белән бергә бирелгән документларны Комиссия, Нигезләмәнең 2.5. пунктына нигезләнеп, гаризалар бирү срогы тәмамланган вакыттан алып 14 календарь көне эчендә карап тикшерә.

Конкурс 16 августтан 26 августка кадәр уздырыла.»;

5.5. пунктны «Тавышлар тигез булганда, Комиссия рәисенең тавышы хәлиткеч булып тора.» җөмләсе белән тулыландырырга;

5.6. пунктта «агымдагы елның 10 октябренә кадәр срокта» сүзләрен «Комиссия беркетмәсе рәсмиләштерелгән көннән алып ике көнлек срокта» сүзләренә алмаштырырга;

5 нче бүлекне түбәндәге эчтәлекле 5.8. пункт белән тулыландырырга:

«5.8. Комиссиянең карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр суд тәртибендә Россия Федерациясе законына туры китереп белдерелергә мөмкин».

Министр А.М.Сибагатуллин